**13.02.2017** **284-р**

**Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның берсүзсез үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының 13.02.2017
елның 284-р номерлы карары
белән расланды

**Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрдән җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: торгларсыз гына җир кишәрлеге алырга хокукы булган физик һәм юридик затлар, соралган җир кишәрлеген булдырырга кирәк булган яисә җир кишәрлегенең чикләре төгәлләштерүне таләп иткән очракта да.

Дәүләт хезмәтен алырга гариза бирүчеләр булып хезмәтне алучылар яисә тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә дәүләт хезмәте алучы исеменнән эш йөртүче затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) санала.

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 71 номерлы автобуслар белән «Калинин» тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: 221-40-39, 221-40-89.

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – Интернет челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

Электрон почта адресы: mzio@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ЖК) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4147 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 25.10.2001, № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4148 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, №31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 06.04.2011 № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, №15, 2036 б кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 29, 4344 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012, №601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, 2338 б.);

«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын электрон документ формасында әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын әзерләүгә һәм территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасының форматына таләпләрне, кәгазь документ формасында әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасының формасын раслау турында» 27.11.2014, № 762 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 762) (Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru 18.02.2015, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында алдан килешү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү ысулларын һәм тәртибен раслау турында һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген, шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып гариза бирү, шулай ук аларның форматларына куелган таләпләр турында” 14.01.2015, № 7 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 7) (“Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы” (www.pravo.gov.ru) 27.02.2015);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ЖК) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1, 4 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм

боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы,. 2007, № 37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында” 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 19.10.2011, № 39, 1928 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибе турында” 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибе (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл (шәһәр) җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) дөреслеккә туры килмәвенә китерүче министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Мөрәҗәгатьнең киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдән җир кишәрлекләре бирү турында алдан килешү | РФ ҖК Ст. 39.15;<br>ТР ҖК;<br>п. 3.3.19 Нигезләмә |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | п. 3.3.19 Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | 1. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар.<br>2. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар. | РФ ҖК п.7 ст.39.15;<br>п. 3.3.19 Нигезләмә |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать кергәннән соң утыз календарь көненнән дә артык булмаган срокта күрсәтелә.<br>Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында соңрак кергән мөрәҗәгатьне карау срогы алдан юлланган яки тапшырылган җир кишәрлеге урнашу схемасы раслану турында карар кабул иткәнче яисә күрсәтелгән схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнче туктатылып тора. | РФ ҖК п.7 ст.39.15<br><br>РФ ҖК п.6 ст.39.15 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, шул исәптән, электрон формада һәм аны күрсәтү тәртибе | 1. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать (1 нче кушымта).<br>2. Гариза бирүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр тапшырылган башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән исемлектә каралган документлар, вәкаләтле органга ведомствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибендә бирелә торган документлар искәрмә булып тора.<br>3. Соралган җир кишәрлеген ясарга кирәк булган һәм әлеге җир кишәрлеге ясаласы чикләрнең территориясен ызанлау проекты булмаган очракта, җир кишәрлегенең урнашу схемасы.<br>4. Урман кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза бирелгән булса, урман кишәрлекләренең проект документациясе.<br>5. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать итә икән, вәкилнең вәкаләтләрен раслаган документ.<br>6. Гариза бирүче чит ил юридик заты булса, юридик затның чит дәүләтнең законнарына туры китереп дәүләт теркәве узуы турындагы документларының рус теленә расланган тәрҗемәсе.<br>7. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында | РФ ЖК п.2 с.39.15 |

| | | |
|---|---|---|
| | яисә җир кишәрлеген түләүсез файдалану турында мөрәҗәгать оешмага бакчачылык өчен тәгаенләнгән булса, гражданнар төзегән коммерциячел булмаган оешманың әгъзалары исемлеге. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда саклланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар саклланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1. Бинага, корылмага хокук турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);<br>2. Җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);<br>3. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);<br>4. Гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән).<br>Гариза бирүче алда күрсәтелгән документларны үзе дә китерә ала.<br>Гариза бирүченең алда күрсәтелгән документларны | РФ ҖК 39.15 ст. 2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Документларны вәкаләте булмаган затның бирүе.<br>2. Мөрәҗәгатькә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның беркетелмәгән булуы.<br>3. Мөрәҗәгатьтә һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартылган, өстәп язылган һәм төзәтелгән урыннар булуы.<br>4. Документларның башка вәкаләтле органга тапшыру. | РФ ҖК 39.15 ст. 3 п. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр:<br>Әгәр дә Министрлыкка кергән җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгатькә беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасы, | РФ ҖК 39.15 ст. 6 п. |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләрнең тулы исемлеге | башка затның алдарак тапшырылган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгатенә беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасына өлешчә яисә тулысынча туры килсә.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгатькә беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасы РФ ЖК 11.10 статьясындагы 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча раслана алмый;<br>2) ясаласы җир кишәрлеге гариза бирүчегә РФ ЖК 39.16 статьясындагы 1 - 13, 15 - 19, 22 һәм 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә алмый;<br>3) чикләре 218-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп төгәлләштерүне таләп иткән җир кишәрлеге РФ ЖК 39.16 статьясындагы 1 - 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә алмый. | РФ ЖК 39.15 ст. 8 п. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торган түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br><br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | РФ Президенты Указы № 601, п. 1 |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | Мөрәҗәгать кергән бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазы һәм мәгълүмати стенд куелган бүлмәләрдә башкарыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка таләпләр | Инвалидларга каршылыксыз керә алу, шул исәптән каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге белән тәэмин ителә, шул исәптән тиешле урынга килеп җитә алу максатында объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>мәгълүмати стендларда һәм “Интернет” челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләрне инвалидлар | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | каршылыксыз керә алырлык итү;<br>инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу.<br><br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>әлеге Регламентның Министрлык белгечләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы.<br><br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша юллаганда – бер көннән дә артык түгел;<br>дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br><br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яисә телефоннан) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша белешә ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала.<br>Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора. | № 63-ФЗ Федераль закон<br>№ 210-ФЗ Федераль закон<br>Боерык № 7 |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күпфункцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

1) Гариза бирүчегә консультация бирү;
2) мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;
3) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату;
4) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында Министрлык карары проектын яисә җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар проектын әзерләү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллауны да кертеп;
5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 4 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте күрсәтелү тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга бәйле башка мәсьәләләр буенча гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (мөрәҗәгать теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатен Бүлеккә тапшыра (юллый) яисә күрсәтелгән документларны почта аша юллый.

Мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документлар техник мөмкинлекләр булганда №7 Боерык таләпләренә туры китереп, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора.

3.3.2. Бүлек белгече:

мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итә;

Бүлеккә тапшырылган мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документларна алганда вәкилнең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесне раслаучы документларны карый, гариза бирүче исеменнән эш башкаручының вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә) тикшерә;

тапшырылган мөрәҗәгатьне һәм документларны (документларның күчермәләрен) тикшерә.

Гариза бирүче документларның расланмаган күчермәләрен бирсә, Бүлек белгече аларны төп нөсхәсе белән чагыштыра һәм күчермәләрне үз имзасы белән раслый.

Мөрәҗәгать РФ ҖКның 39.15 статьясындагы 1 пункты нигезләмәләренә туры килмәсә, башка вәкаләтле органга тапшырылган булса яисә мөрәҗәгатькә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлмәсә, Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән аңлатма белән бергә, гариза бирүчегә кайтара.

Мөрәҗәгатьне һәм аңа беркетелгән документларны кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарту өчен нигез булмаса, Бүлек белгече бирелгән документларны тикшереп чыкканнан соң түбәндәгеләрне башкара:

Гариза бирүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә документларны кабул итү яки аларны кабул итүдән баш тарту турында язып куя (язуның тәртип номеры, кабул итү датасы һәм минуткача төгәллек белән вакыты, документларның

гомуми саны, гариза бирүче турында мәгълүмат, гариза бирүченең мөрәҗәгате максаты, үз фамилиясе һәм инициаллары);

мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар исемлеген теркәп куя (җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгатькә 1 нче кушымта);

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать үтү битен тутыра (2 нче кушымта);

гариза бирүчегә мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар исемлегенең беренче нөсхәсен бирә;

мөрәҗәгатьне, кергән документлар, мөрәҗәгать үтү бите һәм мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар исемлегенең икенче нөсхәсе белән бергә, теркәү өчен, Министрлыкның контроль һәм эш башкару бүлегенә (алга таба – Эш башкару бүлеге) юллый.

Процедура нәтиҗәсе: тикшерелгән һәм Эш башкару бүлегенә юлланган мөрәҗәгать һәм документлар яки документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.3. Эш башкару бүлеге белгече Бүлеккә тапшырылган, шулай ук, почта аша килгән мөрәҗәгатьне һәм аңа беркетелгән документларны рәсмиләштерә, керү номеры суга һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.3 пунктларында билгеләнгән процедуралар граиза бирүче тарафыннан мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар бирелгән көнне карала.

Почта аша килгән мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар әлеге Регламентның 3.3.2 пунктында күрсәтелгән тәртиптә, мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар кергән көнне карала

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар.

3.4. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында Министрлык карары проектын, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында Министрлык карары проектын яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында карар проекты (алга таба – туктату) әзерләү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведоствоара запрослар формалаштыру һәм юллауны да кертеп;

3.4.1 Бүлек белгече туктату өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә. Туктату өчен нигез булса, Бүлек белгече туктату турында карар проекты әзерли һәм туктату турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллый.

3.4.2. Бүлек белгече ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада запрослар юллый:

1. бинага, корылмага хокук турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);

2. җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);

3. юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);

4. гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән).

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедурадан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: белешмә бирү турында запрослар.

3.4.3. Ведомоствоара арадашлык органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән запрослар нигезендә билгеләнгән срокта соралган документларны (белешмәләрне) бирәләр.

Процедура нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булган документлар, белешмәләр яисә Министрлыкка юлланган баш тарту турында белдерү.

3.4.4. Бүлек белгече ТР буенча ФСХИдан, ТР Росреестрдан әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләр килгәч, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган нигезләрнең булу-булмавын тикшерә;

җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында Министрлык карары проектын (алга таба – килештерү турында карар проекты) яки җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында, баш тарту нигезләре һәм ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелгән Министрлык карары проекты (алга таба – баш тарту турында карар проекты) әзерләү;

килештерү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге пункт билгеләгән процедуралар юлланган запросларга җавап алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган килештерү турында карар проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.4.5. Бүлек мөдире килештерү турында карар проектын, баш тарту турында карар проектын яисә туктату турында карар проектын карый, килештерә һәм килештерү өчен Җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире килештергән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган килештерү турында карар проекты, баш тарту турында карар проекты яисә туктату турында карар проекты.

3.4.6. Идарә башлыгы килештерү турында карар проектын, баш тарту турында карар проектын яисә туктату турында карар проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.4.5, 3.4.6 пунктлары билгеләгән процедуралар алдагы процедурадан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән килештерү турында карар проекты, баш тарту турында карар проекты яисә туктату турында карар проекты.

3.4.7. Туктату турында карар проектын Идарә башлыгы белән килештергән көнне Бүлек белгече әлеге карарны министрның беренче урынбасарына кул куярга юллый.

3.4.8. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән килештерү турында карар проектын, баш тарту турында карар проектын хокукый экспертиза үткәрү өчен Хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура, аннан алдагы процедура беткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, Хокук идарәсенә юлланган килештерү турында карар проекты, баш тарту турында карар проекты.

3.4.9. Хокук бүлеге белгече килештерү турында карар проектына, баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый (шул исәптән, проектның коррупциягә каршы экспертизасын) һәм килештерелгән карар проектын яисә әлеге проектлар буенча (кимчелекләр булса) хокук идарәсе бәяләмәсен килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү турында карар проекты, баш тарту турында карар проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе (кимчелекләре булса) яисә хокук идарәсе белгече белән килештерелгән килештерү турында карар проекты, баш тарту турында карар проекты.

3.4.10. Хокук идарәсе башлыгы килештерү турында карар проекты яки баш тарту турында карар проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсенә имза куя, яисә килештерү турында карар проектын яки баш тарту турында карар проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү турында карар проекты яки баш тарту турында карар проекты буенча Хокук идарәсе бәяләмәсе яисә килештерелгән килештерү турында карар проекты яки баш тарту турында карар проекты.

3.4.11 Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта, булган кимчелекләрне бетерә һәм килештерү турында карар проектын яки баш тарту турында карар проектын килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.4.12 Хокук идарәсе башлыгы хокук бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекнең бетерелүен тикшерә һәм проектны килештерә.

3.4.13. Бүлек белгече имза салу өчен министрның беренче урынбасарына - килештерү турында карар проектын яки баш тарту турында карар проектын, карар проектына кушып язылган хатны юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Министрның беренче урынбасарына юлланган килештерү турында карар проекты яки баш тарту турында карар проекты.

3.4.14. Министрның беренче урынбасары килештерү турында карар проектын, баш тарту турында карар проектын яисә туктату турында карарны имзалый һәм аларны теркәү өчен Эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары имзалаган һәм теркәү өчен Эш башкару бүлегенә юлланган килештерү турында карар проекты, баш тарту турында карар проекты яисә туктату турында карар.

3.5. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Эш башкару бүлеге белгече килештерү турында карарны, баш тарту турында карарны яисә туктату турында карарны терки, гариза бирүчегә телефон аша шалтыратып килештерү турында карар, баш тарту турында карар яисә туктату турында карарны бирү вакыты турында хәбәр итә, яки килештерү турында карар, баш тарту турында карар яисә туктату турында карарны гариза бирүче күрсәткән почта адресы буенча юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Эш башкару бүлегендә теркәлгән һәм гариза бирүчегә юлланган килештерү турында карар, баш тарту турында карар яисә туктату турында карар.

3.5.2. Гариза бирүче килештерү турында карар, баш тарту турында карар яисә туктату турында карарны алырга килсә, документларны тапшыру буенча җаваплы булган Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

вәкилнең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен раслаган документларын тикшерә; юридик зат исеменнән гамәл кыла алу вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

вәкилгә килештерү турында карар, баш тарту турында карар яисә туктату турында карарны тапшыра һәм исәпкә алу кенәгәсенә карарның бирелүе турында язып куя.

Әлеге пункт билгеләгән процедура вәкил килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган килештерү турында карар, баш тарту турында карар яисә туктату турында карар.

3.6 Дәүләт хезмәте электрон фолрмада, күп функцияләр башкаручы үзәк аша, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннары аша күрсәтелми.

3.7. Хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү.

Гариза бирүченең килештерү турында карарда техник хатаны төзәтү буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

3.7.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать;

килештерү турында карарның төп нөсхәсе;

Техник хата булуын таныклаган документлар.

3.7.2. Килештерү турында карарда техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне гариза бирүче шәхсән үзе яки аның законлы вәкиле шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый (шул исәптән, электрон почта аша).

3.7.3. Эш башкару бүлеге белгече беркетелгән документлары белән бергә гаризаны кабул итеп ала да, Бүлеккә бирә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура мөрәҗәгать һәм документлар китерелгән (кергән) көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм рәсмиләштерелгән мөрәҗәгатьнең карау өчен Бүлек белгеченә юллануы.

3.7.4. Бүлек белгече документларны карый да, Килешүтерүгә үзгәрешләр кертү максатыннан, Килештерү турында карарга үзгәрешләр кертү проекты әзерли һәм әлеге Регламентның 3.4.4 – 3.4.9 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яки теләсә кайсы катнашы булган затның хата турындагы мөрәҗәгатеннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү турында карарга үзгәрешләр әзерләү

3.8. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документларны (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, карарга үзгәрешләр кертү (техник хаталары төзәтелеп) белән бергә) Министрлыкта калган нөсхә янына беркетелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулысынча һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту үз эченә түбәндәгеләрне ала: тикшерүләр үткәрү, гариза бирүченең хокукларын боху очракларын ачыклау һәм бетерү, шикаятьләрне карау, тикшерүләр үткәрү, гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затларының кылган (кылмаган) гамәлләре буенча карарлар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына экспертиза үткәрү;
- документлар кабул итү сроклары һәм тәртибе саклануы буенча тиешле тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү;
- канцелярия эшләрен алып бару буенча тиешле тәртиптә тикшерүләр үткәрү.

Тикшерүләр үткәрү планлы (Министрлыкның ярты еллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр уздырганда хезмәт күрсәтүгә бәйле бөтен мәсьәләләр карала (комплекслы тикшерүләр). Планнан тыш тикшерүләр гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелегенең үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы министр урынбасары, эш башкару бүлеге

белгечләре, шулай ук Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсенең Берләштерү бүлеге белгечләре тарафыннан тормышка ашырыла.

4.3. Контрольдә тотучы вазыйфаи затлар исемлеге Министрлыкның стурктур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр, вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерүгә хокуклы.

Министрның карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Министр урынбасарының кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять министр исеменә бирелә.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада була ала.

5.3. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап юлланырга тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Министрлыкка кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, Министрлык, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең

билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
___________________________________

(кемнән) ________________________________
(физик затлар өчен – фамилия, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булганда), яшәгән урыны, шәхесен раслаучы документ реквизитлары, ИНН

_____________________________________________
(юридик затлар өчен - атамасы,урнашкан урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛда теркәлүе турында мәгълүмат, ОГРН, ИНН)
_____________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

# Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать

Сездән ________________________________________________ нигезендә,
(РФ ҖК 39.3 ст. 2 п., 39.5 ст., 39.6 ст. 2 п., яки 39.10 ст. 2 п. каралган нигезләр күрсәтелә).
________________________________________________________максатларында
(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)

_____________________________________________________________________
(гариза бирүче җир кишәрлеген алырга теләгән хокук төре)

_______ кв.м. мәйданлы, кадастр номеры ________:___, ____________________

файдалануга рөхсәте булган, ________________ категорияле,
________________________________________________ адресы буенча урнашкан
(җир кишәрлегенең урнашу урыны күрсәтелә)

җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүегезне сорыйм.

Өстәмә белешмә (аста күрсәтелгән шартлар булганда тутырыла):
_____________________________________________________________________

дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алынган җир кишәрлегенә алмашка бирелә торган җир кишәрлеге булса, җир кишәрлегенең дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алынуы турында карар реквизитлары;

___

җир кишәрлеге территориаль планлаштыру һәм (яки) территориянең планировка проектында каралган объектларны урнаштыру өчен бирелә икән, территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территориянең планировка проектын раслау турында карар реквизитлары;

___

соралган җир кишәрлегенең ясалуы территорияне ызанлау проектында күрсәтелгән икән, территорияне ызанлау проектын раслау турында карар реквизитлары

Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар теркәлә:

1) гариза бирүченең җир кишәрлеген торглар үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр тапшырылган башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән исемлектә каралган документлар, вәкаләтле органга ведомствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибендә бирелә торган документлар искәрмә булып тора.

2) җир кишәрлегенең урнашу схемасы (*соралган җир кишәрлеген ясарга кирәк булса, чикләрендә әлеге җир кишәрлеге ясаласы территориянең ызанлау проекты булмаган очракта*);

3) урман кишәрлегенең проект документациясе (*урман кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать бирелсә*);

4) гариза бирүченең вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ (*җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать итсә*);

5) юридик затның чит дәүләтнең законнарына туры китереп дәүләт теркәве узуы турындагы документларының рус теленә расланган тәрҗемәсе (*гариза бирүче чит ил юридик заты булса*);

6) гражданнар төзегән коммерциячел булмаган оешманың әгъзалары исемлеге (*оешма җир кишәрлеген бакчачылык өчен файдалануны сорап, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында яисә җир кишәрлеген түләүсез файдалану турында мөрәҗәгать иткән булса*).

Гариза бирүченең имзасы (_______№__________________________ышанычнамә буенча вәкил
__________________________________________/_______________________/
(вәкилнең фамилия, имя, этисе исеме (соңгысы – булганда), имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"_________ 20__ г.
______/__________________/гаризаны алган Бүлек белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский

ур., 26 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Искәрмә: Персональ мәгълүматларны эшкәртү турында әлеге гариза физик зат тарафыннан бирелә.

Гариза бирүченең имзасы (_______№_________________________ышанычнамә буенча вәкил _______________________________________/_______________________/
(вәкилнең фамилия, имя, этисе исеме (соңгысы – булганда), имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"_________ 20__ г.
______/_________________/гаризаны алган Бүлек белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштырудан катнашырга рөхсәтемне бирәм ________________________.

________________ ___________________ ( ___________________)
(дата) (имза) (Ф.И.ӘИ.(соңгысы - булганда)

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
турында мөрәҗәгатькә
1 нче кушымта

# Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында
**мөрәҗәгатькә теркәлгән документлар исемлеге**

| Документлар атамасы | Битләр саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил )
___________________________________________
_____________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече
_____________________________________ ________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)
Бөтен документлар 1 данәдә тапшырыла.

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында
җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында
**мөрәҗәгать үтү**
**бите**

Гариза бирүче ______________________________________________
Регистрация (керү) номеры __________________________

| № п/п | Министрлык бүлекчәләре | Кабул итеп алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| 2. | Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 5. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 8. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 9. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | килештерү һәм имзалау) | | | | |
| 10. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 11. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны рәсмиләштерү һәм теркәү) | | | | |

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
_______________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:___________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Дөрес белешмә:_____________________________________________________
___________________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегезне һәм «____»_________ 20______ел. №________ карарга тиешле үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм. Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.


Дәүләт хезмәте күрсәтелү турында (баш тарту турында) мәгълүматны ___________________________________________________________________________
(язмача, электрон почта белән,
_________________________________________________________________алырга риза.
Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка)

______________ ________________ (________________)
(дата) (имза) (Ф.И.ӘИ. (соңгысы - булса))

М.П. (мөһер булса)

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

## Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



**Бүлек белгече**

Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы килештергән килештерү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертизага юллый.

Хокукый экспертизага юлланган килештерү турында карар проекты яисә баш тарту турында карар проекты

**Хокук идарәсе белгече**

Килештерү турында карар проектына яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый.
3 көн

Бәяләмә проекты (кимчелекләр булган очракта) или килештерү турында яисә баш тарту турында килештерелгән карар проекты

**Хокук идарәсе башлыгы**

Бәяләмәне имзалый яки килештерү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә.
1 көн

Килештерү турында яисә баш тарту турында килештерелгән карар проекты

Имзаланган бәяләмә

**Бүлек белгече**

Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне бетерә һәм килештерү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Хокук идарәсенә юллый.
1 көн

Килештерү өчен Хокук идарәсенә юлланган килештерү турында карар проекты яисә баш тарту турында карар проекты

**Хокук идарәсе башлыгы**

Килештерү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә.
1 көн

Килештерү турында яисә баш тарту турында килештерелгән карар проекты

**Бүлек белгече**

Килештерү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юлланган килештерү турында яисә баш тарту турында карар проекты

**Министрның беренче урынбасары**

Килештерү турында карарны, баш тарту турында карарны яисә туктату турында карарны имзалый һәм теркәү өчен Эш башкару бүлегенә юллый
1 көн

Имзаланган килештерү турында карар, баш тарту турында карар яисә туктату турында карар

Туктату өчен нигез булган шартларның туктатылуы

Эш башкару бүлеге белгече

Килештерү турында карарны, баш тарту турында карарны яисә туктату турында карарны терки һәм гариза бирүчегә юллый
1 көн

Килештерү турында кул куелган карар яисә баш тарту турында карар

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмәлек)

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм контрольдә тотучы
вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-89 | Artur.Galiev@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе мөдире<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |
| Идарә башлыгы урынбасары<br>Аксанов Валерий Аркадьевич | 264-76-89 | Valeriy.Aksanov@tatar.ru |